**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт, Актаныш ав.,423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ  КАРАР

______________  __________

**2021-2022 уку елында ДОСААФ һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә белгечләр әзерләү нәтиҗәләре һәм 2022-2023 уку елына бурычлар турында**

«Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 53-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1999 елның 1441 номерлы «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләү турында нигезләмәне раслау турында» карары һәм Татарстан Республикасы хәрби комиссариаты билгеләгән план-бирем таләпләрен үтәү йөзеннән гражданнарны хәрби-учет белгечлекләре буенча әзерләүгә бирем 100 %ка үтәлде.

Хәрби-учет белгечлекләре буенча әзерләнгән 18 кешенең, 18е Кораллы Көчләргә җибәрелгән, бу 100 % тәшкил итә.

2023 елда чакырылырга тиешле гражданнар арасыннан белгечләрне үз вакытында һәм сыйфатлы әзерләү максатларында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

- чакырылырга тиешле гражданнар арасыннан 2022-2023 уку елына белгечләр әзерләү буенча төп чаралар планы (1 нче кушымта);

- хәрби-учет белгечлекләре буенча әзерлек өчен гражданнарны сайлап алу комиссиясе составы (2 нче кушымта).

2. Актаныш районы хәрби комиссары Л.С. Әхмәтҗановка Актаныш муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнардан чакырылырга тиешле гражданнарны әзерләүне тәкъдим итәргә:

- 2022-2023 уку елында Актаныш технология техникумында һәм Чаллы автомәктәбендә Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты йөкләмәсе нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләре өчен белгечләр әзерләү.

3. Актаныш районы хәрби комиссары Л.С.Әхмәтҗановка уку йортларында укучы һәм Актаныш авылында яшәүче гражданнардан тыш, аларны әзерләүне укудан аерылмыйча гына үткәрергә, производстводан аерылып, белгечләр җыю юлы белән үткәрергә тәкъдим итәргә;

4. Оешмаларның һәм учреждениеләрнең җитәкчеләренә укуга җәлеп ителгән гражданнарга даими эш урыны буенча уртача эш хакы түләү белән эшләү урыннарын сакларга һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 704 номерлы карары нигезендә чыгымнарны түләргә тәкъдим итәргә;

5. Оешма һәм мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренә хәрби хезмәткә чакырылучыларга даими рәвештә дәресләргә йөрү өчен кирәкле шартлар тудырырга, аларның йөрешен һәм өлгерешен контрольдә тотуны тәкъдим итәргә;

6. Районның халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә билгеләнгән тәртиптә эшсез дип табылган вакытлыча эшләмәүче хәрби хезмәткә чакырылучылар арасыннан гражданнарны хәрби-исәпкә алу белгечлеге буенча әзерлек оештырырга тәкъдим итәргә;

7. Актаныш технология техникумы директорына, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге җитәкчесе белән берлектә, курсантлар белән физик әзерлек буенча дәресләр оештырырга тәкъдим итәргә;

8. Актаныш районы хәрби комиссары Л.С. Әхмәтҗановка даими рәвештә Россия Федерациясе Кораллы Көчләре өчен белгечләр әзерләүнең барышы турында Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә хәбәр итүне тәкъдим итәргә. Актаныш районы хәрби комиссарының 2022-2023 уку елына Россия Федерациясе Кораллы Көчләре өчен белгечләр әзерләү планын үтәү барышы турындагы мәгълүматын апрельдә - беренче укыту агымын әзерләү нәтиҗәләре буенча, сентябрьдә - уку елы нәтиҗәләре буенча тыңларга;

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче РА.Ильясов

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
карарына
_________202_ № ______
1 нче кушымта

**2022-2023 уку елында Актаныш муниципаль районы гражданнарын хәрби-учет белгечлекләре буенча әзерләү буенча төп чаралар планы**

| № т/б | Чаралар | Башкаручы | Башкару срогы |
|---|---|---|---|
| **1. Оештыру чаралары** | | | |
| 1. | Тормыш иминлеге нигезләрен оештыручы укытучылар, психологлар, сыйныф җитәкчеләре, урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучы яшьләргә хәрби-һөнәри юнәлеш бирү мәсьәләләре буенча консультация бирү, инструкторлык-методик дәресләр үткәрү, ярдәм күрсәтү һәм консультацияләү | хәрби комиссариат | 10.09.22 елга кадәр |
| 2. | Актаныш технология техникумында белем алу өчен кандидатларны сайлап алу мәсьәләләре буенча авыл җирлекләре башлыклары урынбасарлары катнашында инструктор-методик дәрес үткәрү | хәрби комиссариат | 10.09.22 елга кадәр |
| 3. | Хәрби-учет белгечлеге буенча кандидатларны сайлап алу | хәрби комиссариат | 20.09.22 елга кадәр<br>20.03.23 елга кадәр |
| 4. | Хәрби учет белгечлеге буенча укырга җибәрелүче гражданнарга медицина тикшерүе үткәрү | хәрби комиссариат | 20.09.22 елга кадәр<br>20.03.23 елга кадәр |
| 5. | Вазыйфаи затлар белән хәрби учет белгечлеге буенча әзерлек өчен җаваплы булган укыту-методик җыемнар үткәрү | хәрби комиссариат | 01.10.22 елга кадәр |
| 6. | Уку төркемнәрен туплау | хәрби комиссариат | 01.10.22 елга кадәр<br>01.04.23 елга кадәр |
| 7. | Учреждение предприятиеләре җитәкчеләренә курсантларның йөреше һәм өлгереше турында мәгълүмат белән тәэмин итү | хәрби комиссариат | укыту чоры дәвамында |
| 8. | Гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү мәсьәләләре буенча Актаныш технология техникумының җитәкче һәм укытучылар составы белән инструктор-методик җыеннар үткәрүдә катнашу | Хәрби комиссариат, Актаныш технология техникумы | даими |
| 9. | Актаныш технологик техникумының укыту-матди базасын камилләштерү | Актаныш технология техникумы | даими |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10. | Белем бирү учреждениеләренең, коралларның һәм хәрби техниканың һәм мөлкәтнең укыту-матди базасының торышын контрольдә тотуны гамәлгә ашыру | хәрби комиссариат | даими |
| 11. | Актаныш технология техникумы өчен производствога өйрәтү осталары составына кандидатлар сайлау | Хәрби комиссариат, Актаныш технология техникумы директоры | даими |
| 12. | Актаныш технологик техникумында 837 номерлы хәрби учет белгечлеге буенча укулар үткәрү:<br>укытуның беренче агымы;<br>- «С» категориясе йөртүчесе - 6 кеше | Хәрби комиссариат, Актаныш технология техникумы директоры | октябрь-февраль |
| | 2 нче укыту агымы;<br>- “С” категориясе йөртүчесе - 3 кеше | Хәрби комиссариат, Актаныш технология техникумы директоры | март-июль |
| 13. | Актаныш технология техникумында чыгарылыш имтиханнарын үткәрү:<br>укытуның беренче агымы; | Хәрби комиссариат, Актаныш технология техникумы директоры | март |
| | укытуның икенче агымы; | Хәрби комиссариат, Актаныш технология техникумы директоры | июль |
| 14. | Актаныш технология техникумында шәхси һәм комплекслы тикшерүләр уздыруда катнашу. | хәрби комиссариат | тикшерүләр барышында |

*Искәрмә: Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан турыдан-туры буйсынмаган башкаручылар план буенча килешүгә кертелә.

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
карарына
______ _________ 2022 ел,
2 нче кушымта

**Актаныш муниципаль районында хәрби-учет белгечлекләре буенча гражданнар сайлау комиссиясе составы**

**Комиссия рәисе:**

| | |
|---|---|
| Әхмәтҗанов Л.С. | Актаныш районы хәрби комиссары. |
| **Комиссия әгъзалары:** | |
| Нуруллина Г.М. | Актаныш районы хәрби комиссариатының хәрби комиссарының (профессиональ психологик сайлап алу һәм гражданнарны хәрби хезмәткә чакыруны оештыру буенча) өлкән ярдәмчесе; |
| Шамсунова Л.Җ. | Актаныш технология техникумы директоры; |
| Шакирова Р.М. | Мәгариф идарәсе башлыгы; |
| Вәлиев Л.Ә. | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы. |

Искәрмә: Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә турыдан-туры буйсынмаган комиссия вәкилләре килештерү буенча комиссия составына кертелә.